Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!

# Татарстан коммунисты

№2 (36). 2013 ел, 8 май. КПРФның Татарстан региональ бүлеге иҗтимагый-политик газетасы




## ЯЗ ҺӘМ ХЕЗМӘТ БӘЙРӘМЕ




1 май – Яз һәм Хезмәт бәйрәме. Дөньяның 142 илендә 1 Май – Халыкара эшчеләр бердәмлеге көне. 1886 елның 1 маенда АКШ һәм Канаданың күп шәһәрләрендә, кешеләр эш көнен сигез сәгатькә калдыруны сорап митингларга һәм демонстрацияләргә чыкканнар. Чикагода демонстрацияне куган вакытта 4 кеше һәлак була. Шуннан соң полициягә каршы протестлар башлана. Протестларның берсендә бомба шартлаталар һәм дәвам иткән атышуда сигез полицейский үлә, дүрт кеше төрле җәрәхәтләр ала. Шартлауда дүрт кешене гаеплиләр һәм аларны үлем җәзасына хөкем итәләр. Берничә ел үткәннән соң, хөкем иткән кешеләрнең гаепсез булуы ачыклана. Һәм 1889 елда II Интернационалның Париж конгрессында, хөкем ителгән кешеләрнең истәлегенә, 1 май көнен Халыкара эшчеләр бердәмлеге көне дип игълан итәләр.

**Рәсемдә: быелгы 1 май бәйрәмендә коммунистлар Казан шәһәрендә оештырган митингтан күренеш.**



## Түбән Камада – конференция

**Бирегә КПРФ Татарстан региональ бүлеге җирле бүлекчәсендә беренче секретарь Альберт Яһудин җитәкчелегендәге яңа команда эшли.**

19 апрельдә Түбән Кама шәһәрендә беренче секретарь Х.Г. Миргалимов җитәкчелегендә КПРФның Татарстан Рескомы бюросының күчмә утырышы булып үтте. Утырыш тәгәлләнгәннән соң Түбән Кама җирле бүлеге конференциясе узды.

Конференция эше барышында анда катнашучылар яшерен тавыш бирү юлы белән шәһәр комитетының яңа составын (11 кеше), бюро һәм контроль-ревизия комиссиясе членнарын сайладылар.

Оештыру пленумында КПРФның Татарстан региональ бүлеге Түбән Кама җирле бүлекчәсе беренче секретаре итеп бертавыштан Түбән Кама шәһәр Советы депутаты Альберт Әхмәтвәгыйзович Яһудин сайланды.

Конференция эше йомгаклары буенча карар кабул ителде, анда түбәндәге юллар бар:

КПРФның Татарстан региональ бүлеге Рескомы беренче секретаре Х.Г. Миргалимовның «КПРФның Татарстан региональ бүлеге Рескомы һәм контроль-ревизия комиссиясенең III берләштерелгән пленумы (март, 2013) йомгаклары һәм Түбән Кама шәһәр комитетының, башлангыч оешмаларның һәм һәрбер коммунистның пленум карарларын үтәү буенча бурычлары турында»гы докладын һәм КПРФның Татарстан региональ бүлеге Рескомы секретаре А.А. Яһудинның «Түбән Кама җирле бүлегендәге эчке политик вәзгыять турында»гы докладын тыңлап, фикер алышканнан соң, КПРФның Түбән Кама җирле бүлеге конференциясе карар бирә:

Яңа сайланган Түбән Кама шәһәр комитеты һәм контроль-ревизия комиссиясенә, барлык җирле бүлекчәләргә, һәр коммунистка – КПРФның XV съезды, XX Татарстан отчёт-сайлау партия конференциясе, КПРФның Татарстан региональ бүлеге Рескомы һәм контроль-ревизия комиссиясенең III берләштерелгән пленумы (март, 2013) карарларын үз эшендә игътибарга алырга һәм карарларны үтәү өстендә эшләргә.

## КПРФның Татарстан рескомы III пленумы



Ул 30 март көнне Казан шәһәрендә булып узды.

Пленумда «КПРФның XV съезды карарларын үтәү буенча КПРФның Татарстан Рескомы, аның барлык җирле һәм башлангыч бүлекчәләренең, һәрбер коммунистның бурычлары турында» һәм «КПРФның Татарстан региональ бүлегендәге политик ситуация турында»гы мәсьәләләр каралды.

Пленум эшендә РФ Дәүләт Думасы депутаты, КПРФ Үзәк Комитеты Президиумы члены В.С. Шурчанов, РФ Дәүләт Думасы депутаты В.П. Пешков, КПРФ Үзәк Комитетының партия-оештыру һәм кадрлар белән эшләү бүлегенең сектор мөдире В.Ю. Кузнецов катнаштылар.

Доклад белән Рескомның беренче секретаре **Х.Г. Миргалимов** чыкты. Ул, атап әйткәндә, КПРФның февраль аенда узган XV съездында Г.А. Зюганов ясаган докладның төп положениеләренә тукталды. КПРФ Үзәк Комитеты Председателе анда дөньяда һәм Россиядә бара торган процессларга объектив анализ ясап кына калмыйча, көчәеп килүче кризис шартларында алга таба ничек эш итәргә кирәклеген дә билгеләгән иде. Илдә политик властьны яулап алу төп бурыч булды һәм шулай булып кала да. Съездда Президент администрациясе вәкиле Морозовның да булуы бүгенге көндә җәмгыятебездә Компартиянең әһәмияте никадәр зур булуын ассызыклый.

Х.Г. Миргалимов: «Җирле бүлекләрдәге һәрбер коммунистның бурычы – ел дәвамында кимендә бер кешене партия сафларына керергә әзерләү, – дип билгеләп үтте. – Ел башыннан алып, 40тан артык кешене без партиягә алдык. Татарстанда КПРФ сафларын сан ягыннан арттыру өстендә җитди эш алып барасы бар.

Бүген безнең булган көчләрне консолидацияләү максатында эшләү кирәк. Татарстан Рескомы бу еллар дәвамында ныклык һәм чыныгу мәктәбе узды, без үз-үзебезне яклый алдык, сафларыбызны саклап калдык. Республика партия бүлеге күптән түгел генә Юстиция министрлыгында теркәлде, ә «оппонентлар» дип аталучылар әле дә булса Рескомга каршы газеталарын һәм листовкаларын күтәреп йөриләр. Алар бирегә бер дә конструктив тәкъдимнәр белән килмәде!»

**В.И. Кострин,** Рескомның партия-оештыру һәм кадрлар белән эшләү буенча икенче секретаре: «Семигинчылар партиябезне коммерция рельсларына күчерергә теләгән X съезд кузгалып китү ноктасы булып тора. Шундый ук сценарийны алар Татарстан региональ бүлегендә 2004 елда ук тормышка ашырырга теләп караганнар иде, тик партиядән чыгарылдылар. Ул вакытта беренче секретарь булып сайланган Х.Г. Миргалимов эшне «нуль»дән башлады. Берни дә юк иде бит: партучёт та, оештыру техникасы да, транспорт та, бина да. «Семигинчылар бацилласы» 2007 елда тагын бер тапкыр үзләрен күрсәтте: сайлаулар алдыннан кайбер секретарьлар партия исемлегендәге урыннардан канәгать булмауларын белдерде, алар сайлаулар узгач та тынычланмадылар. Мин бүгенге пленум бу мәсьәләдә нокта куярга, сафларыбызны чистартырга һәм алга таба эш итәргә тиеш дип саныйм. Безнең проблемалар бу кешеләрдән башка да аз түгел. Матди-техник базаны ныгытуны дәвам иттерәсе бар, барыннан да бигрәк, КПРФ Рескомының үз бинасын булдырырга кирәк».

Фикер алышуларда катнашучылар XX республика отчёт-сайлау партия конференциясе, КПРФ Үзәк Комитеты Президиумы карарларын һәм беренче секретарь Х.Г. Миргалимов эшен шәхсән хупладылар. «Партия дисциплинасын бозучыларга карата иң кырыс партия җәзасы бирелергә тиеш», – фикер алышуларда чыгыш ясаучыларны менә шундый идея берләштерә иде.

**В.Ю. Кузнецов,** КПРФ Үзәк Комитетының партия-оештыру һәм кадрлар белән эшләү бүлегенең сектор мөдире: «Барыннан да элек, депутатлар вертикаленең ролен ныгытырга кирәк һәм конкрет проблемалар буенча бергәләп эшләү таләп итәлә, Чистайдагы ДОСААФ мәктәбенең ябылу проблемасы кебек, мәсәлән. Партия матбугатының эчтәлеге турында да уйланасы бар, ул көн кадагындагы проблемаларны күтәрә торган, кызыклы булырга тиеш, газетада «депутат бите» дә кирәк. Җирле бүлекләр, КПРФтан сайланган барлык дәрәҗәдәге депутатлар белән ныклы элемтәдә тору зарур».

**В.С. Шурчанов,** Дәүләт Думасы депутаты, КПРФ Үзәк Комитеты Президиумы члены: «XV съезд дүрт елга партиянең яңа җитәкче органы составын сайлап куйды. Кемдер партия карарлары белән бәлки килешеп тә бетми торгандыр, әмма син КПРФ сафында член булып торасың икән, аны кабул итәргә дә тиеш. XX республика отчёт-сайлау партия конференциясе белән дә шулай ук. Бүген Миргалимов – беренче секретарь, сезнең бюро составы, республика комитеты, контроль-ревизия комиссиясе бар. Карарлар белән килешеп бетмәүчеләр булса да, син күпчелекнең ихтыярына да, Съезд карарларына да, XX отчёт конференциясе карарларына да буйсынырга тиеш. Әмма арада килешмәүчеләр һәм үзләрен буйсынырга мәҗбүр итә алмаучылар да булырга мөмкин. Устав бу очракта да тыныч юл белән хәл итү юлын күрсәтә: ул кеше гариза яза да партиядән чыга, чөнки үзен күпчелеккә буйсындыра алмый. Син партиядән чыгуга, КПРФ таркалачак дип, күкрәк төяргә кирәк түгел. Таркалган ди! Партия тере организм ул, тәнкыйть һәм үзтәнкыйть аша, оештыру һәм идеологик формалар аша үсешнең яңа баскычына чыгарга үзендә көч табачак».

Пленумда катнашучылар КПРФның Татарстан региональ бүлеге Рескомы бюросы һәм КРК Президиумының 2013 елның 23 мартында чыгарган «КПРФның Татарстан региональ бүлегенә каршы таркатуга китерә торган эшләрнең инициаторларын һәм эш алып баручыларын КПРФ сафларыннан чыгару турында»гы карарын бертавыштан диярлек (бер генә «каршы» булды) расладылар. КПРФ Уставын бозган өчен (КПРФ Уставының 5.3, 6.2, 6.7 пунктларындагы таләпләрне үтәмәү) А.Р. Вәлиев, Т.И. Гурьева, Н.Н. Максимов, Р.Г. Садыйков, Н.К. Столярова КПРФ сафларыннан чыгарылдылар.

## ХӨРМӘТЛЕ ВАТАНДАШЛАР!

**Иптәшләр!**

**Чын күңелдән сезне совет халкының Бөек Ватан сугышында Җиңү бәйрәме белән котлыйм.**

**Аны Брест крепостен саклаучылар көттеләр, аңа ышандылар. Аның хакына совет солдатлары Ржев астында һәлак булдылар, блокададагы Ленинградны саклadылар, Одесса һәм Севастопольне, Киев һәм Смоленскины саклап үлемгә бардылар. Җиңүгә ышаныч белән партизаннар һәм подпольедагылар басып алучыларга каршы көрәштеләр. Тыл хезмәтчәннәре һәм «сугыш чоры балалары» шул хыял белән яшәделәр. Шуның белән Мәскәү һәм Сталинград стеналары буеннан Орёл, Курск һәм Белгород, Украина һәм Белоруссия, Бухарест һәм Варшава аркылы Кызыл Армиянең каһарман сугышчылары Берлинга бардылар.**

**Тормыш исбатлады: совет халкын җиңеп булмый икән!**

**Без бу бәйрәмне каты бәрелешләрдә яуладык, илебезгә бөек держава гимнын алып кайттык, Җиңү Байрагын югары күтәрдек, героик рус һәм совет тарихын саклауга күкрәгебез белән бастык.**

**Без ышанабыз, болар барысы да яңартылган социализмга, тынычлыкка, иминлеккә һәм безнең халкыбызның лаеклы тормышына юл башы булды.**

**Ныклы сәламәтлек, яхшы тормыш һәм уңышлыклар телим сезгә, хөрмәтле ватандашлар!**

**Г.А. ЗЮГАНОВ.**
**КПРФ Үзәк Комитеты Председателе.**




**Кадерле татарстанлылар!**
**Хөрмәтле ветераннар!**

Бөек Ватан сугышында Җиңү – совет халкының бөек батырлыгы һәм даны ул! 9 май, бездәге буржуаз власть аның әһәмиятен түбәнсетергә, Бөек Җиңүнең әйдәүчесе һәм рухландыручысы булган Сталин исемен пычратырга никадәр генә тырышмасын, Россиядә барыбер иң кадерле бәйрәмнәрнең берсе булып кала бирә. Волградка үзенең чын исемен – Сталинградны кайтарырга вакыт!

Бөек Җиңүнең 68 еллык бәйрәме белән, кадерле дуслар!

**Х.Г. МИРГАЛИМОВ,**
**КПРФның Татарстан рескомы I секретаре.**

# Яңа курс кирәк!

**КПРФ Үзәк Комитеты Председателе, Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасында КПРФ фракциясе җитәкчесе Г.А. Зюгановның 2013 елның 17 апрелендә Дәүләт Думасында РФ Хөкүмәте отчёты вакытында ясаган чыгышы.**

Узган атнада «Правда» һәм «Советская Россия» газеталарында басылып чыккан «Иллюзияләр күләгәсендәге кризис» дигән мәкаләмдә илдә килеп туган хәлгә киң анализ бирелә. Ул хөкүмәт отчёты алдыннан чыкты. Бик күп кайтавазлар килде. Бу анализның йомгаклары коточкыч хәвефле. Без хәзерге социаль-экономик курс дәвам иткән очракта, Россиягә тулы таркалу янаганлыгы турында бөтен җәмгыятьне кисәтергә тиешбез.

Тамырдан үзгәрешләр көтелә, тулы бер эпоха алышына. Агрессив-спекулятив капитализм кризис газапларында тартыша. Менә шуңа күрә дә бүген вәзгыятькә төгәл һәм гадел бәя бирү, үсешебезнең перспективасын аңлау бик мөһим.

Кыскача гына тарих. Исегезгә төшерәсем килә: 2009 елда Ярославльдә узган Бөтендөнья политик форумында Медведев илдәге хәлгә шактый ук дөрес һәм гадел бәя биргән иде. Аның әйткән фикерләреннән өзек китерәм: илне чимал тупигына куалап керттеләр, аңа модернизация бик кирәк, коррупция дәүләт властенын барлык органнарын зарарлады. Көчле команда һәм бик тә нәтиҗәле эш таләп ителә.

Күп газапларга дучар ителгән Россиябез гражданнары илебездә чып-чын модернизация җәелдерелер дип өметләнделәр. Чөнки барлык дәрәҗә даирәләрдә дә җәмгыятькә җитди вәгъдәләр бирелде. Әйтик, Путин 25 миллион заманча яңа эш урыннары булдыруны таләп итте. Ә үзе нинди тармакта, ничек итеп булдырырга икәнен әйтмәде. Безнең оборонаны ныгытуга 20 триллион сум акча да вәгъдә ителде, шуның 5 триллионы авиация һәм ВПКның фәнгә аеруча бәйле тармаклары өчен билгеләнгән. Алай гына да түгел, сайлау алды кампаниясендә аның тарафыннан халыкка көчле социаль ярдәм күрсәтеләчәге турында да вәгъдәләр әйтелде. Аның бәясе 6 триллион сумга якын иде. Шунда ук торак проблемасын хәл итү, мәгарифне һәм сәламәтлек саклау өлкәсен, авыл хуҗалыгын үстерү буенча берничә проект та халыкка җиткерелде.

Вакыт узды, хәзер, әйдәгез, илнең реаль тестә нәрсә ала алганлыгын санап карыйк.

**Экономика.** Бирелгән вәгъдәләрне тормышка ашыру өчен власть иң кимендә биш процентлы үсешкә ирешергә тиеш иде. Агымдагы елның беренче кварталында экономик үсеш 1 процентка кадәр кимеде, ә промышленность производствосы күрсәткечләре бөтенләй «минус»ка тәгәрәде. Бер үк вакытта бездә тагын бер миллион кеше эшсез калды. 300 меңнән артык кече һәм урта эшмәкәр бөтенләй бөлде. Бары тик коррупционерлар гына чәчәк ата: власть аларга каршы никадәр шарран ярып көрәшсә, алар шулкадәр тизлек белән арта гына бара.

**Финанс** мәсьәләләрендә ни хәлләр соң? Шушы ук беренче кварталда Россиядән 25 миллиард доллар, ягъни 750 миллиард сум акча читкә «шуды», шул ук вакытта хөкүмәт нефть-газ керемнәренең 900 миллиард сумын чит ил банкларына юнәлтте. Производствоның кискен кимүе казнадан 450 миллиард сумны «суырып алды». Нәтиҗәдә, узган кварталда илебез 2 триллион сумын югалтты.

Ә хәзер, әйдәгез, бурычларга бәйле хәлләргә күз салыйк. Дәүләтнең тышкы һәм корпоратив бурычлары 623 миллиард долларга җитте. Узган ел ул бурычлар иң югары тизлек белән үсә барып, 17 процентка җиткән иде. Шуңа өстәп, региональ бурычларны да онытмаска кирәк: ел башына аның күләме 1 триллион 400 миллиард сум тәшкил итә иде инде. Бу сан агымдагы елның беренче өч аенда тагын 500 миллиард сумга артты. Республикаларны, край һәм өлкәләрне акчасызлык тәмам гаҗиз итте. Ә бит илебезнең алтын-валюта фонды да 70 миллиард долларга якын «корыды», бүген ул тышкы бурычлардан 109 миллиард долларга кимрәк исәпләнә. Күргәнебезчә, бу яклап та хәлләр ах итәрлек!

Турысын әйтергә кирәк, илдә яңа дефолт исе килә. Шушындый шартларда **хөкүмәт ни-нәрсә белән мәшгуль соң?** Ул исә, алдын-артын уйлап тормыйча, Россияне Бөтендөнья Сәүдә оешмасына (ВТО) сөйри, шуның белән аз-маз әләгеп калган машина төзелеше тармагын һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләрен дә җимереп бара. Армияне тар-мар итте. Милицияне полициягә әйләндерде. Коммуналь өлкә дә моңа кадәр күз күрмәгән, колак ишетмәгән талау белән мәшгуль, болай да хәерчеләнгән халык җилкәсенә капиталь ремонтны йөкләде. Янгыннарның һәм урманнардагы башбаштаклыкларның бөтен Россиягә җәелүенә теләктәшлек күрсәтә. Илгә мигрантлар агылу процессына бернинди контроль юклык җинаятьчелекнең коточкыч үсүенә китерә. Мондый политикасы белән власть үзе үк әкренләп милләтара каршылыклар тудырырга этәргеч бирә.



Ил, чынлыкта, криминаль полигона, сәүдә-чимал биржасына әверелде. Инде эре милекнең 90 проценты чит илләр контроле астында тора. Без хәзер байлыгыбызны чит илләргә кудыра торган «насос»ларга моңа кадәр булмаган дәрәҗәдә бәйле. Россия экспортында чимал ресурсларының өлеше 90 процентка якынлашты. Машиналар, җиһазлар, азыктөлек, дарулар кертү инде бар булган чикләрне узып китте. Без гади генә әйберләрне дә җитештерүдән туктадык.

Шунысын да ассызыклап әйтәсем килә, инде нефть-газ комплексы да нигездә чит илдә җитештерелгән җиһазлар белән эшли. Аларны чит илдән кертүдә нинди дер өзеклек туа калса, икеөч ай эчендә башка бөтен эш тә тукталачак.

Хөкүмәт ирекле төстә хәрәкәт итү һәм эшче көчләрнең мобильлеге турында сүз алып барганда, Россия Тимер юллары регионара 235 маршрутны гамәлдән чыгара. Хәтта 1895 елдан бирле өзеклексез йөреп торган Әстерхан – Волгоград поездын да туктаттылар. Бу инде асылда яңа крепостное право кертелә дигән сүз.

Бу ситуациядән чыгу юлын хөкүмәт нидә күрә соң? Һаман да шул бер үк нәрсәдә: кемнәндер талап алырга, кемнедер куркытырга, ә үзенекеләргә ни дә булса бирергә дә була... Бөтен җитешмәгән нәрсәне тагын халык җилкәсенә йөкләргә дигән тәкъдим бар, ә аның исә дүрттән өч өлеше болай да очын очка ялгап көчкә дөнья тарта. Барлык социаль чыгымнары: мәгарифкә, сәламәтлек саклауга, халыкның аз тәэмин ителгән катлавына дигәнен һаман кыскартырга. Һәм аннары милекмөлкәтне, шул исәптән, стратегик мөлкәтне сатып җибәрергә. Акчаны чит илләргә чыгаруны дәвам итәргә. Шул ук вакытта безнең бу кертемнәр буенча алынган керем узган елда 2 проценттан кимрәк булды. Үзебез чит илләрдән 5 – 8 процентлы кредитлар алабыз, аны эш кешеләренә 12 – 15, ә кайчагында хәтта 20 процент белән бирәбез. Мондый шартларда бер генә тармак та нормаль үсеш ала алмый.

Югары уку йортларын җимерү дәвам итә. Министрлар «чинушлары» хәтта Фәннәр академиясен бетерергә тәкъдим итәләр. Күчемсез милек өчен налогларны күтәрергә җыеналар, моныcы исә үзләренең кечкенә генә фатирларын хосусыйлаштырган дистәләрчә миллион гражданнарга кагылачак.

Мин инде чираттагы оятсызларча алдауга кайтып калган пенсия реформалары турында әйтеп тә тормыйм. Уртача хезмәт хакының 40 проценты күләмендәге Европа стандартлары буенча минималь саналган пенсиягә ирешү өчен кешегә 30 ел тырмашырга кирәк. Бу әле югары уку йортларында укыган, армиядә хезмәт иткән, нәни бала тәрбияләгән елларны кертмичә! Өстәвенә, пенсия яшенә җиткәч тә тагын биш ел эшләргә! Бер үк вакытта ил буенча уртача саналган 27 мең сумнан аз гына күбрәк хезмәт хакы алырга. Ә бит андый хезмәт хакы күләргә тәтеми: машина төзелешендә ул – 17-18, ә авыл хуҗалыгында 10-12 мең сум тәшкил итә. Культура, мәгариф, медицинада да шундыйрак хезмәт хакы. Ягъни илебез байлыкларын тудыручы гражданнарның төп массасы хәтта шул кечкенә күләмле пенсияне дә ала алмаячак дигән сүз.

Шушы җимергеч курсны тагын да ныгыта төшү өчен җәмгыятебезгә политик «модернизация» дә тәкъдим итәләр: сайлаусыз сайлаулар сыйфатында. Партия системасы ниндидер ботка-боламыкка, винегретка әйләнә. Ә сайлаулар – административ башбаштаклыкка, криминаль төркемнәрнең ярышына, информацион көчләүгә кайтып кала. Бүген үк инде алты дистәдән артык партия теркәлде, тагын йөз партия әле чиратта тора. Бюллетень урынына сайлаучылар кулына галәмәт озын «Чуров чолгавы» тоттырачаклар, аны исә бер генә КОИБ (комплексы обработки избирательных бюллетеней) та «йотарга» – эшкәртергә сәләтле түгел.

Шул ук вакытта исә идарә итүче югары даирә ниндидер үзенчәлекле реформалар турында торган саен катырак кычкыра. Мәгариф өлкәсендә аларны һаман да шул Голодец, Ливанов һәм Фурсенко дәвам иттерәләр микәнни? Болар бит мәктәпкәчә яшьтәге тәрбия системасын таркатып ташлаган кешеләр инде. Урта мәктәпләрдә рус теле һәм әдәбияты, математика буенча программалар кыскарылды. Нормаль имтиханнар урынына бөтен илнең күңелен болгата торган «Убырлы карчык» – «Баба Яга» – «ЕГЭ» кертелде. Һөнәри белем бирү училищеларында, педагогик, авыл хуҗалыгы, культура-агарту учреждениеләре буенча югары уку йортларында кадрлар әзерләү системасы умырткасыз калды. Фәннәр академиясе коточкыч әдәпсезлек юлы белән җимерттерелә. Академиягә нигез салган кеше Бөек Пётр мондый реформалардан үзенең каберендә мең кат әйләнеп ятканды́р инде, мөгаен...

Ә авыл хуҗалыгын күтәрү белән кем шөгыльләнер икән? Әллә «тумыштан игенче» Дворкович белән «терлекче-юрист» Фёдоровмы? Аның җиде урынбасарының берсе генә дә диярлек агропромышленность комплексы белән җитди шөгыльләнмәде. Департаментлардагы 14 җитәкченең нибары икесенең генә бу эш турында профессиональ күзаллаулары бар. Бер үк вакытта «Росагролизинг»ны прокуратура филиалына әйләндерделәр, «Россельхозбанк» идарәсендә дә ни танылган банкирлар, ни аграрийлар күренми...

Модернизация һәм яңа технологияләр моннан соң да шулай «бөек дефолтник» Кириенко белән «баш приватизатор» һәм илнең бердәм энергетика системасын җимерүче Чубайска ышанып тапшырылыр микәнни инде? Сүз уңаеннан, Чубайсның «Роснано» корпорациясенең турыдан-туры зыяны гына да узган елда 20 миллиард сумнан артып китте. Әмма мондый «убылу»лар дәүләт бюджетынан бик юмарт рәвештә тулыландырылып киләләр. Уртача хезмәт хакы 400 мең сумнан артып китә, бу контораны саклау өчен генә дә 483 миллион сум акча сарыф ителгән. Җитәкче «нанистларны» (нанотехнологлар) транспорт белән тәэмин итеп йөртү генә дә салым түләүчеләргә 855 миллион сумга төшкән! Гаҗәпләнәсемени инде – «Ауди 8» автомобилен арендалау өчен генә дә 1 миллион 600 мең сум акча билгеләнгән ләбаса аларда! Могҗиза! Андый «аренда»ның бер-ике айлык акчасына менә дигән яңа автомобиль дә алып булыр иде бит югыйсә.

Тагын бер кат басым ясап әйтәм. Мондый «Үләт вакытында бәйрәм» экономика, финанс мәсьәләләрендә һәм политикадагы вәзгыять ах итәрлек шартларда алып барыла бит әле. Илдәге гражданнарның күпчелеге тормышының очын-очка көчкә ялгап яшәгән вакытта бит бу!

Кипр сабаклары, Евросоюзның Россиядәге оффшор тарафдарлары белән ни кылануы гына да властька күп нәрсәне ачып салырга, аңлатырга тиеш иде, ләбаса. Ә бит американнар Россиянең нувориш (яңа байлар) һәм чиновникларының, башка оффшорларда капиталны үз кулында тотучыларның исемлеген бастырып чыгарды. Кызыклы факт: бу исемлектә АКШның үз гражданнарыннан башка күп илләрнең вәкилләре бар. Яңа махсус операция әзерләнгәнлеге – әлеге «шук» акчаларны үз оффшорларына күчерергә, коточкыч бюджет кытлыкларын капларга ният итүләре аңлашыла... Американнар аны ничек эшләргә кирәклеген яхшы белә, тулы илләрне һәм халыкларны «раскулачивать» итү тәҗрибәсе аларда җитәрлек. Ә хөкүмәт ул акчаларны илгә кайтару өчен бернинди чара да күрә алмый, хәтта үз чиновникларын да мәҗбүр итә алмый ул.

Бүгенге вәзгыять күп яклап моннан унбиш еллап элек булган вакыйгаларны хәтерләтә. Ул вакытта, 1998 елның маенда, дефолт булырга берничә ай алданрак, КПРФ властьны һәм илне булачак хәлләр турында кисәткән иде бит. Без ул вакытта дефолттан кача алдык. Оппозиция куркыныч янаганы хакында вакытында әйтте, тик безне ишетүче генә булмады. Август аенда булган җимерелүдән соң гына Ельцин Кремльдә барлык йогынтылы көчләрне җыярга һәм Примаков, Маслюков, Геращенко җитәкчелегендәге сул центристлар юнәлешендәге хөкүмәт оештырырга мәҗбүр булган иде.

КПРФ тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру өчен тагын яңа дефолтны көтәргәме инде?!

Компартия ачыктан-ачык әйтә: илгә яңа курс, яңа команда, яңа стратегия һәм яңа информацион политика кирәк. Яңа хөкүмәт – милли-дәүләт мәнфәгатьләрен яклый торган, халык ышанычын казанган хөкүмәт кирәк. Стратегик планлаштырудан, промышленностьта һәм региональ өлкәдә акыллы сәясәттән башка кризистан чыгу мөмкин түгел. Ышанычлы банк системасыннан һәм товар җитештерүчеләр ала алырлык кредитлардан башка. Минераль-чимал ресурсларыннан алынган һәм спирт-аракы промышленностe керемнәренә дәүләт монополиясе урнаштырмый торып, бер генә финанс мәсьәләсен дә хәл итеп булмаячак. Энергия чыганакларына бәяләрне, транспорт һәм торак-коммуналь хуҗалыгы тарифларын тиешенчә көйләми торып, без беркем белән дә көндәшлек итәргә сәләтле түгел. Тагын – авыл хуҗалыгына, кече һәм урта бизнеска нәтиҗәле ярдәм күрсәтми торып. Коррупцияне авызлыкламый, БМО Конвенциясенең чиновникларның законсыз юл белән баюына җаваплылыкны арттыру турындагы 20нче статьясын ратификацияләми торып.

Кадрлар резервын формалаштырмыйча, укытучылар, врачлар, инженерлар, галимнәр турында чын кайгыртучанлык күрсәтелә башламыйча, ягъни дәүләтнең сыйфат ягыннан бөтенләй яңа булган экономик һәм социаль политикасыннан башка бу бурычларның берсен генә дә хәл итү мөмкин эш түгел. Бу Конституция нигезендә Путин белән Медведевның вәкаләтләре бик-бик зур. Бары тик аларның ихтыяр көче генә алар тарафыннан игълан ителгән кадрлар «колодасын» буташтырып йөртергә түгел.

Бары тик дәүләт курсын алыштыру, политик реформа һәм милли мәнфәгатьләрне кайгырта, парламент каршында җаваплылык тоя торган коалицион хөкүмәт оештыру гына кризистан чыгуны, өскә ябырылып килгән дефолттан котылуны тәэмин итәчәк.

Күренекле фантаст-язучылар – бертуган Стругацкийларның эшлексезләрнең, булдыксызларның һәм дилетантларның эш кырган кебек мәш килеп кайнашуын аңлату өчен кулланa торган бик дөрес һәм төгәл сүзләре бар: «коекакеры» («эштер-өштерчеләр») дип атала ул...

Шундый «коекакер»лардан торган, үзләре активлык күрсәткән кебек кылансалар да, илне торгызу өчен берни дә эшләми торган хөкүмәтләрнең либераль каруселен туктатырга вакыт.

# ПАРТИЯБЕЗДӘ ТАРИХИ ВАКЫЙГА

Билгеле булганча, быелның 23-24 февралендә Мәскәүдә КПРФның XV отчёт-сайлау съезды булып узды. Бу турыда без газетабызның узган санында тәфсилләп яздык. Съезд Коммунистлар партиясенең торгызылуына 20 ел тулуга туры килде. Аның эшендә КПРФның барлык региональ бүлекләреннән сайланган 323 делегатның 317се катнашты. 700дән артык кунак арасында дөньяның төрле илләрендәге коммунистик, эшче һәм сул партияләреннән, халыкара оешмалардан 95 делегация бар иде.

КПРФның XV съезды эшендә КПРФның Татарстан региональ бүлегеннән делегат булып катнаштылар: КПРФның республика комитеты беренче секретаре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советында КПРФ фракциясе җитәкчесе Х.Г. Миргалимов, Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутаты В.П. Пешков, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.В. Прокофьев. Партия Үзәк Комитеты составына сайланган яңа членнар арасында Х.Г. Миргалимов (рәсемдә сулдан беренче) һәм А.В. Прокофьев (уңнан беренче) бар.

КПРФ Үзәк Комитетының беренче оештыру пленумында Геннадий Андреевич Зюганов бертавыштан КПРФ Үзәк Комитеты Председателе итеп сайланды.

Беренче оештыру пленумында КПРФ Үзәк контроль-ревизия комиссиясе КПРФның Курск өлкә комитеты беренче секретаре, РФ Дәүләт Думасы депутаты Н.Н. Ивановны КПРФның Үзәк контроль-ревизия комиссиясе председателе итеп сайлады.




## САННАР ҺӘМ ФАКТЛАР

Россиядә Компартиягә 1903 елда В.И. Ленин тарафыннан нигез салына. Партия төрле елларда төрле исемнәр йөртә: РСДРП, РКП(б), ВКП, КПСС. КПРФка 1993 елның февралендә нигез салына. Бүгенге көндә КПРФ членнарының саны ил буенча 157 меңнән арта.

Россия Федерациясе VI чакырылыш Дәүләт Думасының КПРФ фракциясен тәшкил итүче 92 депутаты арасында Нобель премиясе лауреаты, академик Жорес Алфёров, ике тапкыр Советлар Союзы Герое, космонавт Светлана Савицкая, Татарстаннан сайланган фән докторлары Василий Лихачёв, Виктор Пешков һәм башкалар бар.




# Политик отчёт буенча КПРФның XV съезды карары

Үзәк Комитетның политик отчётын тыңлагач һәм аның буенча фикер алышкач, Россия Федерациясе Коммунистлар Партиясенең XV съезды дөньяда киң күләмле экономик, социаль һәм политик үзгәрешләр баруын билгеләп үтте. Капитализм системалы кризисның кискенләшү стадиясенә керде. Халыкара аренада аның агрессивлыгы арта бара. Глобаль хәрби конфликт барлыкка килү шартлары формалашып килә.

Россия җитди сынауларга соң чиктә хәлсезләнгән халәттә керә. Капиталистик реванш нәтиҗәсендә илебез чимал колониясенә әверелде, дөнья олигархиясенә буйсындырылды. Россиядә идарә итүче сыйныф коррупцияләшкән бюрократия, спекулятив капитал һәм оешкан җинаятьчелек симбиозының нәтиҗәсе буларак барлыкка килде. Аның югары даирәсе бердәм олигархия булдырды. Җәмгыятьтәге төп сыйныфларның зәгыйфьлеге һәм бюрократик «власть вертикале»нең көчәюе бонапартистларныкыише политик режим урнаштыру өчен алшартлар тудырды.

Россия эчендәге вәзгыять үсешенең нәтиҗәсе буларак, 2011 елның декабрендә Дәүләт Думасына булып үткән сайлаулардагы коточкыч фальсификацияләр кылынуын әйтергә кирәк. Тавыш бирүләр нәтиҗәләренә ышанмау күмәк протестлар китереп чыгарды. Җәмәгатьчелек ризасызлыгының активлашуына җавап йөзеннән, политик режим буржуаз демократия ярылгыларыннан баш тарта һәм тагын да кырысрак шәхси власть системасына күчә.

Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе эшчеләр, крестьяннар һәм интеллигенциянең мәнфәгатьләрен яклый, властьта хакимлек итүне хезмәт халкы кулына тапшыру һәм Ватаныбызны социалистик үсеш юлы нигезендә кабат торгызу өчен көрәш алып бара. Партиябез үз эшчәнлеген яңартып җибәргәнгә дә егерме ел тулды инде. Ил өчен иң катлаулы вакытта коммунистлар үзләренең илебезгә һәм халкыбызга тугрылыклы икәнлекләрен расладылар.

Соңгы елларда узган сайлауларда партиябезне хуплаучыларның артуы сайлаучыларның безнең позицияләргә, программаларыбызга ышаныч белән каравына дәлил булып тора. КПРФның принципиаль мәсьәләләрдәге позициясе партиябезнең XXI гасыр социализмын төзүгә йөз тоткан Программасында тәкъдим ителгән. «Скважиналарга корылган экономика»дан үсеш экономикасына күчүне тәэмин итәргә сәләтле булган «Кризиска каршы көрәш программасы» да эшләнеп, җәмгыятькә тәкъдим ителде. КПРФ политикасы – Россиядә яшәүче гражданнарның абсолют күпчелегенең политикасы ул.

Отчёт чорында партия тулаем үзе һәм Үзәк Комитет теоретик, агитация-пропаганда, оештыру буенча зур эш башкардылар. КПРФ – иң зур һәм дәрәҗәле оппозицион партия, Россия халкының – патриотик көчләрнең үзәге булып кала бирә. Безнең союзникларыбыз да – киң спектр оешмалар. Алар арасында Ленинчыл Коммунистик Яшьләр Союзы, «Надежда России» дип атала торган Бөтенроссия хатын-кызлар союзы, «Русский лад» Бөтенроссия торгызу хәрәкәте, «Сугыш балалары» хәрәкәте һәм башкалар бар. Европа, Азия һәм Америка илләрендәге тугандаш коммунистик һәм эшче партияләр белән КПРФның элемтәләре ныгыды. СКП-КПСС кысаларында коммунистик партияләрнең үзара хезмәттәшлеге уңышлы үсеп дәвам итә.

Отчёт чорында КПРФ сафлары дистәләгән меңнәрчә яшь коммунистлар белән тулыланды. Власть өчен көрәштә билгеләнгән бурычлар бүген партиянең Россиядәге 81 төбәктә эшләп килүче башлангыч һәм җирле партия бүлекләренең уртак тырышлыгы белән хәл ителә. Социаль-экономик һәм политик вәзгыятьнең катлаулы булуы, җәмгыятьтә киеренкелекнең үсә баруы КПРФтан үз мөмкинлекләрен бар яклап та берләшүне, җәлеп итүне, аның массалар белән актив эшләвен таләп итә. Партиянең оештыру һәм кадрлар структурасы яшәртүгә, ныгытуга һәм камилләштерүгә мохтаҗ. Глобаль капитализм кризисы шартларында һәм тиз үзгәрешләр заманында партиянең программа бурычларын үтәүгә ирешү өчен политик фикерләү тирәнлеге, идея һәм оештыру бердәмлеге, һөҗүмчәнлек, тупланганлык һәм тиз эш итә белү кирәк.

Съезд карар бирә:

1. Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе Үзәк Комитетының отчёт чорындагы эшен канәгатьләнерлек дип бәяләргә.

2. КПРФ Үзәк Комитетының съездга ясаган Политик отчёт докладындагы бәяләмәләрне, нәтиҗәләрне һәм гомумиләштерүләрне хупларга. Гамәли эшчәнлектә алга куелган бурычларны күздә тотып эш итүне зарури гамәл дип санарга.

КПРФның XV съезды резолюцияләрен расларга:

– «Капитализм – кризиста! Киләчәк социализм кулында!»;

– «Хезмәт халкын аның үз хокукларын яклауга күтәрергә!»;

– «Либераль һөҗүмнәргә – юк! Патриотларның бердәмлеге өчен!»;

– «Табигый байлыкларны – халыкка хезмәткә!»;

– «Җирне – игенчеләргә! Авылга – яклау!»;

– «Коммунистлар халык файдасына булмаган хосусыйлаштыруга каршы»;

– «ВТО – Россия халыкларына каршы глобализм агрессиясе коралы ул»;

– «Гаилә һәм балалар – иң югары кыйммәтләр»;

– «Россия яшьләренә – лаеклы киләчәк!»;

– «Көчле армия – Россия иминлегенең нигезе»;

– «Русларның һәм Россиядәге башка халыкларның фундаменталь кыйммәтләрен саклауга»;

– «Яшәсен социалистик Куба!»;

– «Сириядән кулларыгызны алыгыз!».

3. Партиянең барлык бүлекләренә дә – социализм идеалларын массаларга актив кертергә. КПРФ Программасының принципиаль положениеләрен киң күләмдә аңлату эшләрен җәелдерергә. Хезмәт ияләренең, халык массаларының хокуклары өчен көрәштә партияне һәм аның авангардлык ролен ныгытуны мөһим политик бурыч дип санарга. Көндәлек алып бара торган эшчәнлектә иҗтимагый-политик көрәшнең кискенләшүе шартларында партиянең социаль һөҗүмчән булуына җәмгыятьтә таләпнең көчәя баруын истә тотып эш итәргә. КПРФ сафларының ышанычлы үсә баруын, бигрәк тә яшьләр исәбенә тулылануын тәэмин итәргә. Үз эшебездә катгый төстә партия Программасы һәм Уставы таләпләреннән чыгып эш итәргә.

4. КПРФ Үзәк Комитеты Президиумы һәм Секретариатына, партиянең региональ һәм җирле комитетларына кадрлар резервын формалаштыруга игътибарны көчәйтергә. Оештыру-партия эшләренең нәтиҗәлелеген таләпчәнлек белән камилләштерә барырга. КПРФ членнарының идеяполитик дәрәҗәсен күтәрергә. Партия активының идеологик хәзерлек дәрәҗәсен яхшырту максатында, КПРФ Үзәк Комитеты каршында политик укулар үзәгенең даими эшләвен җайга салып җибәрергә. Карьеризм һәм местничество күренешләрен, партия вазыйфаларына кешене шәхси карашлардан чыгып кына билгеләү фактларын тамырдан кисәргә.

5. Агитация-пропаганда чараларының масштабларын киңәйтергә, нәтиҗәлелеген арттыра барырга. Партиянең күмәк мәгълүмат чараларын үстерергә. Подписчикларга яздырып, «Правда» һәм «Советская Россия» газеталарына ярдәм күрсәтергә. КПРФ региональ комитетларының интернет-сайтлары эшен камилләштерергә. «Красная линия» телевизион каналын торгызуны гомумпартия бурычы буларак карарга. Аны мәгълүмат белән тулыландырырга ярдәм итәргә. Средстволар җыюны түбәндәге принцип буенча башкарырга: «Бер көнлек хезмәт хакын – партия телевидениесенә». «Бердәм Россия»нең һәм башка буржуаз партияләрнең сыйнфый чынбарлыгын фаш итү өчен булган бөтен мөмкинлекләрне файдаланырга.

6. Россиядәге сул һәм патриотик халык көчләренең ныклы союзын формалаштыруны мөһимнәрдән мөһим мәсьәлә дип санарга. Партиянең региональ һәм җирле комитетларына – урыннардагы җәмәгать берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлекне тагын да җәелдерергә, алар белән союздаш мөнәсәбәтләрне киңәйтергә. Бу эшне партия сафларын тулыландыру өчен мөһим резерв сыйфатында карарга.

7. КПРФ Үзәк Комитетына, партиянең региональ һәм җирле комитетларына – олигархлар капиталы властена басым ясау ысулларының киң спектрыннан файдаланырга. Политик көрәшнең парламент һәм парламенттан тыш алымнарын аралаштырырга. Массаларның үз хокукларын һәм мәнфәгатьләрен таләп итүнең актив формаларына булган хокукларын якларга. Протест хәрәкәтен үстерүне тәэмин итәргә.

8. Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасындагы, Россия Федерациясе субъектларындагы һәм җирле үзидарәләрдәге закон чыгару (вәкаләтле) органнарындагы КПРФ фракцияләренә – партиянең массаларга йогынтысын көчәйтү өчен парламент мөмкинлекләрен төрле яклап файдаланырга. КПРФның программа тәкъдимнәрен пропагандаларга, аның социаль-экономик һәм политик инициативаларын үстерергә, хезмәт ияләре мәнфәгатьләре хакына көрәшне көчәйтергә. Политик азатлыкның һәм гражданлык хокукларын торгызуны таләп итәргә. Халыкның референдумга булган хокукына тулысынча ирешергә. Политик һөҗүмнең парламенттан тыш формаларын үстерүгә төрлечә булышлык итәргә.

Партия Үзәк Комитетына – КПРФ депутатларының Бөтенроссия съездын әзерләргә һәм уздырырга.

9. КПРФның региональ һәм җирле комитетларына – теләсә нинди дәрәҗәдәге сайлауларга да үз вакытында әзерләнә башларга кирәклегенә игътибарны юнәлтергә. Җирле үзидарә органнарында партия вәкиллекләрен киңәйтергә. Сайлаулар вакытында тавыш бирү һәм йомгак ясау барышына контрольлек итүнең ышанычлы системасын формалаштырырга. КПРФтан квалификацияле күзәтүчеләр һәм сайлау комиссияләре членнары корпусын киңәйтүне оештыру-партия һәм кадрлар белән эшләүнең мөһим юнәлеше дип санарга.

10. Партиянең региональ, җирле һәм башлангыч бүлекләренә – партия оештыручылары институтын формалаштыру буенча эшне көчәйтергә. КПРФ Үзәк Комитеты подразделениеләренә кирәкле булган методик һәм гамәли ярдәмне күрсәтергә.

11. КПРФ Үзәк Комитетына – партиянең халыкара элемтәләрен ныгытуны дәвам итәргә. Прогресс, гаделлек һәм дөньяны социалистик юнәлештә үзгәртеп кору өчен көрәштә коммунистик партияләр һәм башка демократик көчләр белән үзара хезмәттәшлекне һәм тәләктәшлекне киңәйтергә. 2014 елда Коммунистик партияләр Союзының чираттагы съездын әзерләү һәм үткәрү эшендә СКП-КПСС Советына булышлык күрсәтергә.

12. КПРФ Үзәк Комитеты Президиумына, партиянең региональ комитетларына – партиянең матди-техник базасын ныгыту, җирле бүлекчәләрне биналар, транспорт, оештыру техникасы, заманча коммуникация чаралары белән тәэмин итү эшен дәвам иттерергә. Партия средстволарының керемнә һәм чыгымына, КПРФ членнары тарафыннан партия взносларын һәм башка төрле түләүләрне түләүгә ышанычлы контрольне тәэмин итәргә.





# Ветеран һаман сафта

Миргасим Касыймов Азнакай районының Сәпәй авылында 1916 елның 4 октябрендә күп балалы крестьян гаиләсендә туа. Өлкә совет-партия мәктәбен тәмамлый. Казанда берьеллык тарих укытучылары курсын тәмамлап, укытучылык эшендә була. 1940 елда совет-фин сугышы чорында армиягә алына. Бөек Ватан сугышының башыннан ахырына кадәр катнаша. 1947-1965 елларда КПССның Азнакай райкомында, район Советы башкарма комитетында бүлек мөдирләре, КПСС райкомы секретаре һ.б.лар була. Шушы чорда читтән торып Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлый һәм үзенең төп белгечлеге – педагог эшчәнлеге белән шөгыльләнә. «Сугышчан Кызыл Байрак», I-II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары белән бүләкләнә. Отставкадагы капитан. 1939 елдан бүгенгәчә Компартия члены. Актив коммунист. Аның язмалары хәзер дә «Правда» һ.б. газеталарда басыла. Шушы араларда гына аның истәлекләре Казан төзелеш-архитектура академиясе чыгарган китапта дөнья күрде.

Азнакай шәһәрендә яши, Азнакай районының Почетлы гражданины. Миргасим аганы Бөек Җиңү бәйрәме белән чын күңелдән котлыйбыз, аңа ныклы сәламәтлек, озын бәхетле гомер теләп калабыз.

*«Яшәсен Бөек Ватаныбыз! Яшәсен данлы Коммунистлар партиясе! Совет халкына дан!»*

*9 майда бу сүзләр шәһәрләр урамнарында, киң кырларда, хуторларда яңгырады. Сугыш бетү шатлыгыннан бөтен җирдә сугышчылар автоматлар, винтовкалардан атып салют бирәләр, ә кичен исә, караңгыда күккә төрле төстәге ракеталар оча, трофейга әйләнгән, әлегә урында калган немецларның автомат, зенит пушкаларыннан, калган снарядларын һавага аталар, күктә дистәләгән вак йолдызчыклар хасил була. Икенче көн инде сугышчылар йокы белмичә бәйрәм итәләр.* **(М. Касыймов).**

# ЫЗГЫШЛЫ ЙОРТТА БӘРӘКӘТ БУЛМЫЙ

Апрельнең соңгы көннәрендә ТР Дәүләт Советының КПРФ фракциясе, Икенче Бөтендөнья сугышына багышлап, фәнни конференция үткәргән иде. Тарихыбызда иң зур фаҗигаләрнең берсе булган әлеге сугыш хакында нинди генә сүзләр сөйләнмәни, нинди генә китаплар чыкмый, нинди генә фильмнар эшләнми, әмма иң аяныч – сугыш турында хакыйкать заманга яраклаштырылып үзгәртелә тора.

Конференциияне ачып җибәргәндә үк депутат Хафиз Миргалимов: «Инде менә соңгы 20 ел буе Ватан сугышының әһәмиятен, җиңүдә ил җитәкчелегенең, коммунистлар партиясенең ролен бозып күрсәтү бара», – дигән иде. Мин тарихчы түгел, шуңа күрә сугышның башлану сәбәпләрен, җитәкчелекнең ялгышларын бәяләргә җыенмыйм, бары тик конференциядә әйтелгән кайбер фикерләрне укучыларыбызга җиткерергә генә телим.

Россиянең сугышлар тарихы фәне академиясе академигы, профессор, «Хәтер» китабы баш мөхәррире Анатолий Александрович Иванов үз чыгышында нәкъ менә 1990 елларда тарихи фактларны бозып күрсәтү башлануын һәм бүгенгәчә дәвам итүен, моның җәмгыятьнең рухи халәтенә зур зыян салуын әйтеп үткән иде.

Җәмгыять үзгәрү белән идеология дә үзгәрә дибез, ә бүген нинди идеология алып барабыз да кешене нинди рухта тәрбиялибез соң? Россия тарихын нечкәләсәң, патша заманнарыннан алып бүгенге көнгә хәтле ил белән идарә иткән бер генә хаким дә җүнле кеше булмаган икән ләбаса. Ә халык аңа табынып яшәгән. Ни өчен? Әллә «халык – сарык» дигәннәре рас микән? Демократик җәмгыять төзибез дип лаф органда, нинәрсәгә патша самодержавиесен, «Микулай» патшаны сагына башладык икән? Әйткәнемчә, мин тарихка бәя бирмим, бәлки, күңелдә килеп туган уйларымны сорау рәвешендә генә язам.

Әлеге дә баягы профессор Иванов: «Минем әти фронтовик иде, соңгы көннәренә хәтле Александр Солженицынны ни өчен күккә күтәрүләрен аңламады», – диде. Кызыл армияне, илне пычратып язган китапларын чит илдә миллионлаган тираж белән чыгарган, кесәсен долларлар белән тутырган һәм Нобель премиясен алган «демократия атасы»н профессор ни өчен тәнкыйть утына тота икән? Хәзер кинематографиянең «сыекланууын» да әйтеп үтте ул. Сугыш турындагы хәзерге фильмнарда коммунистларның, комиссарларның бары тик тискәре образлар итеп бирелүен дә әйтте. «Ә бит нәкъ менә алар сугышка беренче булып керделәр һәм һәлак булдылар», – диде А. Иванов.

Хәтерлим, 90нчы еллар башында илдә сугыш ветераннарына карата мөнәсәбәт тә үзгәрә башлаган иде. Аларның сугышчан бүләкләрен урамнарда ачыктан-ачык саттылар. Хәтта «аяк астында буталып йөргән» өчен ветераннар тарафына төрле кимсетүле сүзләр дә ычкындыралар иде.

Инде бүген яшь буынны Совет халкының хезмәт һәм сугышчан батырлыгы үрнәгендә тәрбияләп булмый. Дөрес, хәзерге җитәкчелек сугыш ветераннарына кадер-хөрмәт күрсәтергә омтыла, Җиңү көннәрендә аларны олылап: «Без сезнең алда мәңгелек бурычлы», – дигән сүзләр дә яңгырый.

Совет чорының яхшы якларын кире кайтару омтылышы да башланды. Мин ГТО нормаларын тапшыруны, Хезмәт Герое дигән исемнәрне күз алдында тотам.

Һәр илнең киләчәге, алга китеше тарихи хәтер белән, үткәннәрдән дөрес гыйбрәт алу белән бәйле. Әйе, нәкъ менә дөрес гыйбрәт алу. Әгәр дә без тарихны бүгенге идеология, алай гына да түгел, аерым бер төркем идеологиясеннән генә чыгып бәяләсәк, җәмгыять ызгышлардан котыла алмаячак. Россия тарихының бары тик сугышлардан гына торуы үзе үк сәясәтчеләрне, ил язмышы өчен җаваплы кешеләрне уйландырырга тиеш.

Конференциядә «Хәтер» китабын төзүчеләрнең берсе, Казан Кремлендәге «Бөек Ватан сугышы музее» мөдире Михаил Черепанов: «Без «Хәтер» китабын исәннәр өчен чыгарабыз», – дигән иде. Аның әйтүенчә, хәбәрсез югалганнар саны элекке СССР буенча 7 млн тирәсе. Без 20 мең солдатның исемен ачыкладык. «Җиңүнең 70 еллыгына исемсез солдат калмасын иде. Бу хакта президент В. Путинга да җиткердем», – диде М. Черепанов.

Инде менә яңадан Бөек Җиңү көне килеп җитә. Телеэкраннар, матбугат битләре Ватан сугышы тематикасы белән чуарланыр. Әйтергә теләгәнем шул: әлеге чуарлыкны кара төсләр генә басып китмәсен иде. Сугыштан «файда», ягъни сәяси дивидендлар тупланудан туктарга вакыт. Ызгышлы йортның беркайчан да мантый алмаячагын, анда бәрәкәт булмаячагын хәтердән чыгармасак иде.

**Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ.**

(«Ватаным Татарстан», 8.05.2013 ел).

# «БГ» Азнакайга җыена

«Безнең гәҗит»кә 10 яшь! Шул уңайдан редакциябез республикада укучылар саны буенча беренче урында булган район – Азнакайга десант төшерә. 17–18 майларда журналистларыбыз, артистлар катнашында очрашулар үткәчәк. Очрашуларга рәхим итегез, хөрмәтле укучыларыбыз. Очрашу урыннары, вакыты Азанкай радиосы, телевидениесе һәм газетасы аша рекламалана.

**«БГ», 8.05.2013 ел.**

**«Татарстан коммунисты» газетасы редакциясе «Безнең гәҗит»не юбилее белән котлый!**

# Кем бай, кем…

«Forbes» журналы бөтен дөньядагы иң бай кешеләр исемлеген бастырган. Бу юлы анда 4 татарстанлы да кергән. Бу «ТАИФ» холдингы вәкилләре Альберт Шиһабетдинов, Рөстәм Сультеев һәм элеккеге президентыбыз Минтимер Шәймиевның уллары Радик белән Айрат. Алар дүртәүләп исемлекнең ахырындарак тора, чөнки байлыклары артык «күп түгел» – миллиард ярым долларда аз гына ким икән. Бу исемлеккә барысы 1300дән артык кеше кергән. Иң күп миллиардерлар АКШта, икенче урында – Кытай. Үзенең байлары белән Русия Знче урынны били.

**«БГ», 13.03.2013 ел.**

# Яндырылган язмышлар иле – Азнакай…

Узган атна җомгасында, Азнакай район хакимияте каршында, өйлә намазыннан соң озак та үтми, коточкыч вакыйга була: 42 яшьлек Альберт Хәмидуллин үз өстенә бензин сибеп ут төртә. Без шушы хакта ишетеп, бу атнаның дүшәмбесендә әлеге районга сәфәргә кузгалганда, нибары шушы хәбәрне һәм ул ирнең кемда ятуын белә идек. Алдан ук әйтим: вакыйгаларга ачыклык кертергә теләвебез бик җиңел генә барып чыкмады. Бу эшнең җиде кат йозак астына яшерелгән булуы һәм кайбер органнарның массакүләм мәгълүмат чараларына ни рәвешле һөҗүм итүен белергә теләсәгез, язманы ахырына кадәр укып чыгарга киңәш итәм. Бу ирнең үз-үзен үтерерлек хәлгә китерел җиткерүенә сәбәпче булган кешеләр җавап тотачакмы? Миңа калса, юк. Чөнки алай булырга охшамаган. Ни өчен шулай әйтүемне алга таба аңларсыз.

Альбертның һөнәре турында сүз чыккач, аның үз теләге белән эштән китүе турында да сөйләделәр. Альберт эшен бик яраткан. Әле август аена кадәр ул нефтьчелек өлкәсендә бораулаучы булып эшләгән, хәтта аларның бригадасы беренчелекне алып, аларга бик зур премия дә (дөрес булса, бригададагы 5-6 кешегә 200 мең сумнан артык акча дип ишеттек – авт.) түлисе булганнар.

Эшсез калгач Альберт кайларга гына барып карамый, ләкин эш таба алмый. Казанда да таксига урнашырга тели, ләкин «яңа машиналар кайтып җитмәгән» дигән сылтау белән, аны соңрак эшкә чакырырга вәгъдә итеп озаталар.

Бу хәлдән соң халык арасында гайбәт тә бик тиз таралган. Бәлки, озын колаклар яратучы сүз боткасы кемнәрдер тарафыннан махсус күпертеләдер?! Чөнки бу вакыйганы көнендә үк тәшереп алып эфирга чыгарган телеканалларның берсе ирнең хакимият каршында түгел, ә бер торак йорт каршында януын әйтә. Алай гына да түгел, http://directpress.ru интернет сәхифәсендәге шушы темага кагылышлы язмада рәсми аңлатма биргән Азнакай район Советы аппараты җитәкчесе Айдар Хәлиуллин да аның хакимият каршында түгел, ә торак йорт янында януын әйтә һәм сәбәбен гаилә проблемалары белән бәйли. «Ул безгә бернинди ярдәм сорап мөрәҗәгать итмәде», – ди ул. Халык телендә исә «алкоголик, наркоман янган инде шунда», «адекват булмаган, авыру кеше янган», «гаиләсендә ызгыш булган икән, энесе белән фатир бүлгәннәр», «әнисе аны фатирыннан куып чыгарганга шулай эшләгән», «хакимияттә җитәкчеләр 10 көнгә каядыр киткән булган икән, шуңа аны тыңлаучы булмаган» кебек дөреслеккә туры килмәүче һәм инде азнакайлылар арасында киң таралган сүзләр дә кем файдасына очко өстәвен күрсәтеп тора. Димәк сау-сәламәт, исерек булмаган (гәрчә, аның шешә тотып, сыра яки аракы чөмереп торуын әйтүче булмады, тәмәкесен генә күргәннәр), үз гаиләсе өчен янып-көеп яшәгән, дөресрәге яшәргә тырышкан, ләкин шундый рәхимсез җәмгыятьтә үзенә урын таба алмаган ирне авыру һәм наркоман итеп күрсәтү кемгәдер файдалы булып чыга?!

Шулай ук халык арасында «ул хакимияткә кергән, ләкин аны куып чыгарганнар» дигән сүз дә йөри. Нишләптер, менә монысына ышану җиңел. Беренчедән, район хакимиятенең бу эшне йомып калырга маташуы көн кебек ачык. Икенчедән, әле үземне дә ул көнне шундыйрак алым белән «тәрбия кылдылар». Тик хакимият түгел, ә башкалар. Күрәсең, Азнакайда шулай кешене куып чыгару, мәсхәрәләү гадәти хәлдер.

Без Азнакай тикшерү комитетына кереп, бу материал белән шөгыльләнүче өлкән тикшерүче янына кердек. Газетадан булуымны аңлаткач, ул чыгып торырга, көтәргә кушты. Көткән чакта Нәсимә апаның телефоны шалтырады. Ә хәзер әйтегез әле, баласын югалтуын белгән ананы нинди сүзләр белән юатып була?! Тикшерү комитеты бүлекчәсендә Нәсимә апаның кычкырып елаган тавышына бер-ике тикшерүче йөгереп чыкты. Нәсимә апаның дивар буйлап шуып төшкәнен күреп, аны ничек тә күтәрергә, ярдәм итәргә теләдем. Шунда ник бер тикшерүче килеп ярдәм итсен дә, ник берсе бер стакан су бирсен… Аны ишек төбендәге урындыкка утырткач, өлкән тикшерүче янына кереп сөйләшергә булдым.

– Альберт үлде. Ул үләр алдыннан әнисенә соңгы сүзләрен язып калдырган булган. Ул хатны сезнең хезмәткәрләр, кире кайтару шарты белән, аннан алган булган. Ул бит аны хәтта укырга да җитешмәгән. Нигә сез шул хатны анага кире кайтармыйсыз?

– Сез кем соң әле монда? Бар, чыгыгыз моннан, сезне күрәсем килми!

Азнакайда менә шулай сөйләшәләр кеше белән!

– Бу фаҗиганең протест чарасы булуы күренеп тора, мондый эш тик торганда гына эшләнми, – ди шәһәр советы депутаты Рөстәм Сәләхов. – Аның ничек кап-кара төтен белән дөрләп януын үзем күрдем. Эчкече, наркоман кеше янган дип гайбәт тараттылар. Андый кеше хакимият каршына килеп үз-үзенә ут төртә алмый. Район җитәкчелеге кешене ишетсен, аның белән бергәләп, кулга-кул тотынып эшли башласын, аның проблемаларына битараф калмасын өчен ничә кеше хакимият каршына килеп үз-үзенә ут төртергә тиеш?! – ди ул.

**Эльвира ФАТЫЙХОВА.**

Казан-Азнакай-Казан. («БГ», №37, 19.09.2012 ел. Кыскартып бирелә).

**Барлык почта бүлекләрендә дә «ПРАВДА» газетасына язылырга мөмкин. Газетаның индексы: 50102. Ярты елга язылу бәясе: 634,44 сум.**

«Татарстан коммунисты» («Коммунист Татарстана»)
Баш редактор – Хаким ГЫЙЛӘҖЕВ
Техник редактор – Евгений РУЛЕВ
Телефон: 9600623230, факс: (85592) 7-56-46
Электрон адрес: ursai55@rambler.ru,
Сайтлар: www.kprf.ru, tat-kprf.ru

Газетаның учредителе: КПРФның Татарстан региональ бүлеге.
Учредитель һәм редакциянең адресы: 420021, Казан шәһәре, Сул Болак урамы, 56.
Тел./факс: (843) 292-53-26, 292-27-22.
Газета Элемтә, информацион технологияләр һәм күмәк коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республика идарәсендә ПИ №ТУ 16-00314 таныклыгы белән 19.02.2010 елда теркәлде.
Басарга кул кую вакыты: 08.05.2013 ел. график буенча – 14.00, кул куелды – 14.00.

«Бөгелмә типографиясе» ААҖ
423230, РТ, Бөгелмә шәһәре,
Карл Маркс урамы, 32
Телефон: (85594) 4-85-49
Заказ 302. Тираж 15000.
Бәясе ирекле.